КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 июль г.Казань № 532

Татарстан Республикасы яшьләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең төбәк программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 декабрендәге 3581-б номерлы боерыгын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы яшьләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең төбәк программасын (алга таба - Төбәк программасы);

Татарстан Республикасы яшьләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең төбәк программасын үтәү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап формасы.

2. Төбәк программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:

Төбәк программасы чараларын чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча чикләрендә үтәүне һәм Төбәк программасында каралган максатчан күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр, әлеге карар белән расланган форма буенча Төбәк программасын үтәү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Төбәк программасын гамәлгә аәшыру өчен җаваплы республика башкарма хакимияте органнары, шулай ук Төбәк программасында күрсәтелгән оешмалар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат җыярга һәм гомумиләштерелгән мәгълүматны хисап кварталыннан соң килүче айның

15 числосына кадәр Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына тапшырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин